**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 18 июль | № 529

г. Казань

Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре һәм оешмаларында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программаларын эшләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре һәм оешмаларында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программаларын эшләү турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре һәм оешмаларында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программаларын эшләүне оештырырга.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә сәнәгать предприятиеләре һәм оешмаларына хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программаларын эшләү буенча методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре һәм оешмаларына 2015 елның 30 декабренә кадәр әлеге карарның 1 пункты нигезендә расланган Нигезләмә нормаларына туры китереп, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программаларын эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\529.docx